Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданнар И.Н. Никитин һәм Р.Ф. Нәфикова шикаятьләренә бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасына 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләренең, күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымтаның, шулай ук тулаем әлеге карарның конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2019 елның 25 ноябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасына 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләренең, күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымтаның, шулай ук аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча тулаем

әлеге карарның конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар И.Н. Никитина һәм Р.Ф. Нәфикова шикаятьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актның тулаем — кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе, шулай ук аның аерым нигезләмәләренең эчтәлеге буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Ике шикаять тә бер үк предметка кагылышлы булганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерде.

Докладчы судья А.Р. Шакараев мәгълүматын, яклар — гражданка Р.Ф. Нәфикова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты Хокук идарәсенең торак законнары мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары — Э.Я. Тимерханова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең хокукый экспертиза бүлеге баш киңәшчесе Е.В. Кириллов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсенең дәүләт хокукы һәм икътисадны норматив җайга салу бүлекчәсенең баш киңәшчесе Д.И. Абзалова, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы

Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге прокуроры М.А. Филиппова, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы А.Г. Бартенев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар И.Н. Никитин һәм Р.Ф. Нәфикова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасына 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләре, күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымта, шулай ук аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча тулаем әлеге карар белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

1.1. Гражданин И.Н. Никитин Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән тулаем аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча, шулай ук 1 нче ярдәмче программаның ул раслаган III бүлегендәге аерым нигезләмәләре һәм күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымта белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуны күрә, алар нигезендә күпфатирлы йортларны сервис схемасы буенча гамәлгә ашырыла торган һәм бюджеттан тыш чыганаклардан тулысынча финанслана торган видеокүзәтү белән тәэмин итү каралган.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, «“Уютный дом” идарәче компаниясе» ЖЧЖ, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының югарыда күрсәтелгән карарына таянып, йорт яны территориясен видеокүзәтү белән тәэмин итү турында мәҗбүри тәртиптә карар кабул итү өчен гражданин И.Н. Никитин яши торган күпфатирлы йортта яшәүчеләрнең гомуми җыелышын үткәрүгә инициатива белдергән. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, күпфатирлы йортларны видеокүзәтү белән тәэмин итү мәсьәләсе бары тик күпфатирлы йортларның милекчеләре тарафыннан гына хәл ителергә тиеш. Фактта исә, ул уйлаганча, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба шулай ук — Башкарма комитет) дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актта, нәрсә һәм нинди тәртиптә (чиратлылыкка кадәр) видеокүзәтү объекты булырга тиешлеген императив формада билгеләп, шул ук вакытта күпфатирлы йортларда видеокамералар урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен муниципаль бюджеттан финанс чараларын бүлеп бирүне күздә тотмыйча, үтәлеше гавами хакимият органнары компетенциясенә керми торган максатлар һәм бурычлар куя. «1 нче ярдәмче программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 1 нче ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» 1 нче ярдәмче программасына кушымта нигезләмәләре буенча 2017—2019 елларда күпфатирлы йортларда видеокүзәтү үсеше бюджеттан тыш чыганаклардан алынган акчалар хисабына күздә тотыла, шуңа күрә әлеге чараларны гамәлгә ашыру яшәүчеләр хисабына башкарыла. Шул ук вакытта, ул санаганча, куркынычсызлык һәм хокук тәртибен тәэмин итү функцияләре ахыр чиктә муниципаль берәмлекләргә йөкләнгән, димәк, күпфатирлы йортларның видеокүзәтү хезмәтләрен тәэмин итү һәм карап тотуны финанслау муниципаль милектә булган җәмәгать урыннары, парк һәм скверлар, җәмәгатьчелек фикерен белдерү урыннары, социаль өлкә объектларындагы видеокүзәтүне финанслаудан аерылырга тиеш түгел.

Моннан тыш, гражданин И.Н. Никитин Казан шәһәре муниципаль

берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 1.7 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нормалары белән үзара бәйләнештә, чираттагы финанс елы башыннан гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар агымдагы финанс елының 1 июленә кадәр расланырга тиеш, дип күрсәтә. Шул ук вакытта 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыра торган муниципаль программа Башкарма комитетның 2016 елның 21 декабрендә кабул ителгән карары белән расланган иде, бу, аның фикеренчә, бюджетны планлаштыру кагыйдәләрен бозу булып тора.

Шулай ук мөрәҗәгать итүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар кул куелган көннән алып ун көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш, дип билгеләп үтә. Әмма карала торган Башкарма комитет карары бары тик 2017 елның 9 мартында гына басылып чыккан. Шул ук вакытта ул раслаган муниципаль программа 2017—2019 елларга каралган, ягъни фактта ул әле үз көченә кермәгән чорда да гамәлдә була.

1.2. Гражданка Р.Ф. Нәфикова үзенең шикаятендә 1 нче ярдәмче программаның III бүлеге нормалары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуын күрсәтә, ул нигезләмәләр буенча, видеокүзәтү оештыру максатларын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәт күрсәтү форматында видеокүзәтү оештыруны күздә тоткан сервис моделе файдаланыла, аның өстенлеге — видеокамералар һәм башка җиһазлар алу зарурлыгы булмау һәм видеокүзәтү хезмәте заказчысы урлау, җайланмаларга зыян китерү (аларны юк итү, сафтан чыгару) куркынычлыгыннан азат ителә, элемтә предприятиеләре (операторлары) инфраструктурасын җәлеп итеп, 1 нче ярдәмче программаны башкаручы базасында видеокүзәтү урнаштыру кысаларында реаль вакыт режимында видеосурәтләрне һәм архив

видеосурәтләрен кабул итү, эшкәртү, язу, саклау һәм дистрибуцияләү (тарату) системасы булдырыла.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданка Р.Ф. Нәфикова яшәүчеләрдән видеокүзәтү өчен түләү алына торган күпфатирлы йортта яши. Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, ул, үзе яши торган йортта нинди нигездә аның ризалыгыннан башка видеокүзәтү урнаштырылуын ачыклау максатыннан, «”Уют” идарәче компаниясе» ҖЧҖнә мөрәҗәгать иткән, аңа җавап итеп, видеокүзәтү өчен түләү кертү турындагы карар йортта яшәүчеләрнең гомуми җыелышында кабул ителгән иде, дип хәбәр иткәннәр.

Гражданка Р.Ф. Нәфикова, хезмәт күрсәтү форматында видеокүзәтү оештыруны күздә тоткан сервис моделенә кагылышлы дәгъва белдерелә торган нигезләмә фактта җәмәгать тәртибен саклау буенча дәүләтнең конституциячел бурычлары үтәлешен Казан шәһәрендә яшәүчеләргә күчерә, дип саный. Мөрәҗәгать итүче шулай ук «Видеокүзәтү» хезмәте өчен түләү «Фатир өчен башка чыгымнар» исәп-фактура юлына кертелгәнгә күрә, әлеге йортта яшәүчеләрдән мондый акча алу законсыз түләүләрне яшерү булып тора, дип билгеләп үтә.

Моннан тыш, гражданка Р.Ф. Нәфикова фикеренчә, реаль вакыт режимында видеосурәтләрне һәм архив видеосурәтләрен кабул итү, эшкәртү, язу, саклау һәм дистрибуцияләү (тарату) системасын булдыруны күздә тоткан шикаять белдерелә торган норма аның хосусый тормышының кагылгысызлыгына хокукын боза, чөнки, эчтәлегеннән аңлашылганча, аның йортындагы видеокүзәтү камераларыннан алынган видеосурәт аның ризалыгыннан башка реаль вакыт режимында тарала һәм теләгән һәркем «Интернет» челтәре аша аның белән таныша ала.

1.3. Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар И.Н. Никитин һәм Р.Ф. Нәфикова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга

Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасына 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләрен, күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымтаны, шулай ук аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча тулаем әлеге карарны Татарстан Республикасы Конституциясенең 18 (беренче өлеш), 24 (беренче һәм икенче өлешләр), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 36 (беренче өлеш), 48 (өченче өлеш), 49 статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә таныла һәм яклана; Татарстан Республикасы Конституциясе — республиканың Төп законы, Татарстан Республикасының хокукый системасында иң югары юридик көчкә ия, турыдан-туры гамәлдә була һәм Татарстан Республикасының барлык территориясендә кулланыла; Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының хокукый актлары Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килмәскә тиеш; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше йә аларга өстенлекләр билгеләү тыела; һәркем хосусый тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, үзенең намусын һәм абруйлы исемен яклауга хокуклы; законда каралган очраклардан гайре, затның ризалыгыннан башка аның шәхси тормышы турындагы мәгълүматны җыю һәм саклау, куллану һәм тарату рөхсәт ителми; хосусый милек хокукы закон белән саклана.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре

нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары тулаем аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча, шулай ук 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләре һәм күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымта хокук куллану практикасында аларга бирелә торган мәгънәсе буенча финанслау күпфатирлы йортлардагы торак урыннарның милекчеләре хисабына башкарыла торган күпфатирлы йортларны мәҗбүри тәртиптә видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү өчен нигез булып торган, ә аларны гамәлгә ашыру гражданнарның шәхси тормышларының кагылгысызлыгына хокукларын бозуга китергән дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «б» һәм «к» пунктлары) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында булган кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен, җәмәгать иминлеген тәэмин итү өлкәсенә, шулай ук торак законнары мәсьәләләренә кагыла. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый

актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

«Куркынычсызлык турында» 2010 елның 28 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 3 өлеше нигезендә куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәте федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең милли куркынычсызлык стратегиясе, Куркынычсызлык Советы тарафыннан әзерләнә һәм Россия Федерациясе Президенты тарафыннан раслана торган башка концептуаль һәм доктриналь документлар нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән законның 12 статьясы нигезендә җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясенең куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге законнарының үтәлешен тәэмин итәләр.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 2446-р номерлы күрсәтмәсе белән «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясе расланды, аның максаты — муниципаль берәмлекләр базасында (бердәм функциональ һәм технологик стандартлар нигезендә) әлеге мәсьәләләрне хәл итү өчен җаваплы көчләр һәм хезмәтләр эшчәнлеген координацияләүне сизелерлек яхшырту хисабына мөмкин булган куркыныч хәлләрне фаразлауны, мониторинглауны, кисәтүне һәм юкка чыгаруны тәэмин итә торган комплексलы мәгълүмат системасын кертү юлы белән җәмәгать куркынычсызлыгының, хокук тәртибенең һәм яшәү тирәлеге иминлегенең гомуми дәрәҗәсен күтәрү.

Әлеге Концепция нигезләмәләре буенча, җәмәгать куркынычсызлыгын һәм яшәү тирәлегенең иминлеген тәэмин итүнең барлык мәсьәләләре буенча оператив карарлар кабул итү максатыннан мәгълүмат җыю һәм эшкәртү үзәге булган муниципаль берәмлек «Имин шәһәр» комплексын төзүнең һәм үстерүнең нигез дәрәҗәсе булып санала. Шуңа бәйле рәвештә җирле үзидарә

органнарына яшәү тирәлегенең комплекслы куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге бурычларны хәл иткәндә, шулай ук «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү муниципаль программаларын эшләгәндә һәм раслаганда алда әйтелгән күрсәтмә белән расланган Концепция нигезләмәләренә таянып эш итәргә тәкъдим ителгән.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясындагы 1 пункты нигезендә муниципаль программалар муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан раслана; муниципаль программаларны эшләү турында карарлар кабул итү, аларны формалаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе муниципаль хокукый акты белән билгеләнә. Әлеге закон күрсәтмәсен үстерү өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы карары белән Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе расланган, аның 1.6 пункты нигезендә муниципаль программалар Башкарма комитет карары белән раслана.

«Казан шәһәрендә мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре үсеше турында» Казан шәһәр Думасының 2015 елның 3 августындагы 3-44 нче номерлы карары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына «2015—2017 елларга Казан шәһәрендә мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрне үстерү» муниципаль программасын, шул исәптән «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексының муниципаль мәгълүмат системасын гамәлгә ашыру кысаларында да, муниципаль программаны эшләү һәм раслау йөкләнгән.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны кабул итеп, Башкарма комитет федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтләрне законлы рәвештә гамәлгә ашырган, әлеге вәкаләтләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) статьясына нигезләнгән, аның буенча җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның

мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

3.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясындагы 2 пункты нигезендә чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар җирле администрация тарафыннан билгеләнгән срокларда расланырга тиеш. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә кабул ителә торган муниципаль программаларга карата мондый срок Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 1.7 пунктында билгеләнгән, аның нигезендә чираттагы финанс елы башыннан гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар агымдагы финанс елының 1 июленә кадәр расланырга тиеш.

Югарыда китерелгән хокукый нормаларның турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, шуны әйтергә кирәк: «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасы 2017 елдан башлап үзенең гамәлгә ашырылуын күздә тотканлыктан, Башкарма комитетның аны раслаган карары да 2016 елның 1 июленнән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Димәк, дәгъва белдерелә торган карарның 2016 елның 21 декабрендә кабул ителү факты үзеннән-үзе аны кабул иткәндә Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 1.7 пунктында каралган срок бозылуга юл куелган булуын раслый.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 30 сентябрендәге 09-05-05/48843 номерлы хаты белән җибәрелгән дәүләт (муниципаль) программалары нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларын һәм җирле бюджетларны төзү һәм үтәү буенча методик тәкъдимнәрнең 6 пунктыннан аңлашылганча, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 6 статьясы, шулай ук 84, 85, 86 статьялары нигезләмәләре буенча, чыгым йөкләмәләре тиешле бюджетлардан акча алучыларны аларда конкрет күрсәтеп — физик яисә юридик затлар (күрсәтелгән затларның категорияләрен), гавами-хокукый берәмлекләрне, бирелә торган ресурс күләмнәрен яисә мондый күләмнәрне билгеләү тәртибен күрсәткән законнарны, башка норматив хокукый актларны кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килә; муниципаль программалар үзләреннән-үзләре чыгым йөкләмәләрен булдырмыйлар, чөнки алар күрсәтелгән таләпләргә туры килмиләр, шул исәптән тиешле бюджетлардан акча алучыларны конкрет билгеләмиләр. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль программаларны алдан кабул итүгә һәм аларга үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән хокукый җайга салуны билгеләү бюджет турындагы норматив хокукый акт нигезендә бюджет чыгымнарын планлаштыруга бәйле.

«2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру чыгымнары Казан шәһәр Думасының 2017 елның 12 апрелендәге 3-15 номерлы карары белән 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның планлы чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кертелгән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган карарны бу максатлар өчен билгеләнгән сроктан тыш кабул итү бюджет акчаларын хокуксыз сарыф итү өчен шартлар тудырмаган, дип саный. Моннан тыш, Башкарма комитетның шикаять белдерелә торган карарын кабул итү тәртибе буенча Татарстан Республикасы

Конституциясенә туры килми дип тану каралучы 1 нче ярдәмче программа, шулай ук тулаем муниципаль программа кысаларында инде гамәлгә ашырылган чараларның законлылыгын шик астына куярга мөмкинлек бирер иде. Мондый нәтиҗә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең һәм гражданның төп хокукларын һәм ирекләрен яклау, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм аның бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итү кебек конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган карарын аны кабул итү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала. Моның белән Казан шәһәренең җирле администрациясеннән, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып, муниципаль программаларны кабул итү срогы турындагы таләпнең үтәлешен чынлыкта тәэмин итү бурычы алынмый.

3.2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (өченче өлеш) һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясы (3 өлеш) нигезендә, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, дәүләт исеменнән норматив хокукый актны гавами хакимиятнең компетентлы органы тарафыннан халыкка җиткерү таләбе хокукый билгеләнешнең гомумтанылган принцибына бәйле, аның нигезендә дәүләтнең һәм шәхеснең мөнәсәбәтләре билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә хәбәр итү әлеге норматив хокукый актның кабул ителүе һәм бәян ителгән тулы текстының гамәлгә кертелергә тиешлеген аңлата. Шул очракта гына аның гамәлдә булуы кагыла

торган затларга законны белмәү аны бозган өчен җаваплылыктан азат итми дигән гомумхокукый презумпция кагыла. Норматив хокукый актның гамәлдә булуы яисә булмавына карата билгесезлек аны саклауда, үтәүдә һәм куллануда бертөрлелекне тәэмин итә алмый һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара, аны зыянлы максатта һәм башбаштакланып файдалану мөмкинлеген тудыра, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге принципларын бозуга китерә (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы Карар).

Татарстан Республикасы Конституция суды бу конституциячел күрсәтмә кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен яклау гарантияләренең берсе булып тора һәм ул императив характерга ия дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2006 елның 7 мартындагы 19-П номерлы һәм 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы карарлар).

Муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән регламентланган, 44 статьяның 1 өлешендәге 6 пункты белән үзара бәйләнештә 47 статьяның 2 һәм 3 өлешләре эчтәлегеннән күренгәнчә, җирле үзидарә органнарының кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы һәм федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булмаган норматив хокукый актлары, бары тик тиешле муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнгән тәртиптә аларның тулы тексты басылып чыккан очракта гына, гомуми белешмә өчен рәсми рәвештә басылып чыккан дип танылырга мөмкин, алар тарафыннан шул исәптән кабул итү (басылу), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм муниципаль хокукый актлар үз көченә керү тәртибе билгеләнергә тиеш.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан

шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 63 статьясындагы өченче абзацы нигезләмәләре буенча Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар кул куелган көннән алып ун көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Шуңа бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган 1 нче ярдәмче программа расланган 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары, кабул ителгәннән соң, 2016 елның 30 декабреннән дә соңга калмыйча, һичшиксез рәсми бастырып чыгарылырга тиеш иде. Шул ук вакытта ул Казан шәһәре Думасының «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару турында» 2006 елның 17 февралендәге 15-6 номерлы карары белән муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару чыганагы сыйфатында билгеләнгән «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең документлар һәм хокукый актлар җыентыгы»ның 2017 елның 9 мартындагы 8 номерында басылып чыккан.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 63 статьясындагы тугызынчы абзацы нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керүен исәпкә алып, Башкарма комитетның шикаять белдерелә торган карары, шулай ук аның тарафыннан расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасы кебек үк, 1 нче ярдәмче программа да аның кысаларында гамәлгә ашырыла, кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына турыдан-туры кагылышлы норматив хокукый акт буларак, бары тик рәсми басылып чыкканнан соң, ягъни 2017 елның 9 мартыннан гына кулланылырга тиеш.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны билгеләнгән срокны бозып бастырып чыгару үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуны күрсәтми

һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча аны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану өчен һичшиксез һәм җитәрлек нигез булып тормый, ә бары тик аның үз көченә керү срогының соңрак булуын аңлата, дигән нәтиҗәгә килә.

4. Татарстан Республикасын хокукый дәүләт дип игълан итеп, Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен иң зур хәзинә буларак тану, үтәү һәм яклау бурычын йөкли (1 статьяның беренче өлеше һәм 2 статья). Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы, дип беркетә (22 статья); Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый (51 статья). Күрсәтелгән конституциячел нигезләмәләр шул исәптән җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларның эчтәлеген һәм мәгънәсен билгелиләр.

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезләмәләре буенча муниципаль программа муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенең бурычлары, башкару сроклары, башкаручылары, ресурслары буенча һәм максатларга иң нәтиҗәле ирешүне һәм бурычларны хәл итүне тәэмин итүче планлаштырылган чаралар комплексын үз эченә алган стратегик планлаштыру документы булып тора (35 пункт).

Дәгъва белдерелә торган 1 нче ярдәмче программа нигезләмәләренең эчтәлегеннән күренгәнчә, ул «Имин шәһәр» комплексын төзү һәм үстерүнең беренче чираттагы чараларын гамәлгә ашыруны, «Имин шәһәр» комплексы сегментларын алга таба гамәлгә кертү максатларыннан тотрыклы инфраструктура булдыруга юнәлтелгән оештыру-техник чаралар башкаруны

күздә тота. Вакыйгаларны һәм инцидентларны мониторинглауга, ачыклауга, идентификацияләүгә һәм фаразлауга юнәлтелгән аппарат-программа чараларын, мәгълүмат системаларын, техник чараларны гамәлгә кертү һәм куллану хисабына җәмәгать куркынычсызлыгы, хокук тәртибе һәм яшәү тирәлеге иминлегенең гомуми дәрәҗәсен күтәрү 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның максаты булып тора. 1 нче ярдәмче программа белән беркетелгән бурычларны хәл итү кысаларындагы чараларның берсе — күпфатирлы йортларда һәм алар биләп торган җир кишәрлекләрендә видеокүзәтү үсеше, ул булган вакыйгаларны кисәтү, ачыклау һәм идентификацияләү, элегрәк булган вакыйгалар динамикасын торгызуга юнәлдерелгән программа-аппарат чаралары комплексын үз эченә ала. 1 нче ярдәмче программаның турыдан-туры эчтәлегеннән күренгәнчә, видеокүзәтү оештыру планлаштырылган күпфатирлы йортларның саны якынча һәм аңа ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Шуның белән үзенең хокукый табигате һәм турыдан-туры эчтәлеге буенча 1 нче ярдәмче программаның шикаять белдерелә торган нигезләмәләре бары тик тәкъдим итү характерындагы, күпфатирлы йортларда видеокүзәтү оештыруга ярдәм оештыру-техник якын килүне гамәлгә ашыру механизмын тәэмин итүгә юнәлдерелгән гомуми күрсәтмәләрне генә күздә тота. Шул ук вакытта өстенлекле тәртиптә видеокүзәтү объектлары булып күпфатирлы йортның яки бер төркем күпфатирлы йортларның йорт яны территориясе тора, шул исәптән барлык кварталга керү һәм чыгу урыннарын, халык күпләп була торган территорияләрне (балалар, уен, спорт мәйданчыклары), автотранспорт парковкаларын, каты көнкүреш калдыклары җыю нокталарын, бер төркем күпфатирлы йортларның гомуми панорамасын видеоконтрольдә тоту тәэмин ителә.

Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясы нигезендә күпфатирлы йорттагы фатир өлешләрен тәшкил итмәгән һәм әлеге йортта бердән күбрәк урынга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән урыннар, аерым

милекчеләрнеке булмаган һәм әлеге йортта урын милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән башка биналар, аларның ялын, мәдәни үсешен, балалар иҗатын, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләрен һәм моңа охшаш башка чараларны оештыру өчен билгеләнгән бүлмәләрне дә кертеп, шулай ук әлеге йорт урнашкан, яшелләндерү һәм төзекләндерү элементлары белән, җир кишәрлеге һәм шушы йортка хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен билгеләнгән һәм шушы җир кишәрлегендә урнашкан башка объектлар күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми өлешле милек хокукындагы гомуми мөлкәте булып тора.

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 1.1 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми милкен тиешле тәртиптә тоту Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш һәм күпфатирлы йортның ышанычлылыгына һәм иминлегенә, гражданнарның тормыш һәм сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең иминлегенә һәм башкаларга карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш. Уртак милекне карап тотуның хокукый шартлары Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы өченче өлеше буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта уртак милекне карап тоту кагыйдәләре белән билгеләнгән, алар нигезендә биналар хуҗалары уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча гамәлләрне мөстәкыйль башкарырга яки күпфатирлы йорт белән идарә итүнең сайланган ысулын исәпкә алып, уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару өчен башка затларны җәлеп итәргә хокуклы (12 пункт), шулай ук гомуми җыелышта хезмәтләр һәм эшләр исемлеген, аларны күрсәтү һәм башкару шартларын, аларны финанслау күләмен расларга тиешләр (17 пункт).

Әлеге эшкә карата китерелгән хокукый җайга салу эчтәлегеннән күренгәнчә, күпфатирлы йортны видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү

мәсьәләләрен хәл итү мондый йорттагы урыннар милекчеләренең аерым хокукы булып торуын аңлата. Шул ук вакытта видеокүзәтү системасын кертү турындагы карар, видеокүзәтү хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аның өчен түләү күләме кебек үк, әлеге милекчеләрнең гомуми җыелышында билгеләнгән тәртиптә кабул ителергә һәм тиешле беркетмә белән рәсмиләштерелергә тиеш. Россия Федерациясе Торак кодексының 44 статьясындагы 1 өлешенең һәм 46 статьясындагы 5 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре мәгънәсе буенча күпфатирлы йорт белән идарә итү органы буларак күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары күпфатирлы йорттагы барлык урыннар милекчеләре өчен, шул исәптән тавыш бирүдә катнашмаган милекчеләр өчен дә мәҗбүри булып тора.

Мондый алым Россия Федерациясе Югары Суды тәҗрибәсенә туры килә, ул, «видеокүзәтү» хезмәте өчен күпфатирлы йортта урын милекчеләренә түләү исәпләүнең законлылыгы турындагы мәсьәләне карап, күпфатирлы йортта видеокүзәтү хезмәтләренең үзенчәлеге аларның аерым милекчеләргә индивидуаль күрсәтелүен күздә тотмый дигән нәтиҗәгә килде; видеокүзәтү системасын урнаштыру гомуми мөлкәтне тиешле тәртиптә тотуга, урыннар милекчеләренең иминлеген һәм мөлкәтен саклауны тәэмин итүгә, ягъни күпфатирлы йорт белән идарә итүгә турыдан-туры юнәлдерелгән хезмәт булып тора (2017 елның 20 июнендәге 11-КГ17-13 номерлы Билгеләмә).

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасының 1 нче ярдәмче программасы, аның хокукый статусын һәм эчтәлеген исәпкә алып, гражданнарга күпфатирлы йортларны видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү бурычын йөкләми, күпфатирлы йортларда видеокүзәтү системасын урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүгә кагылышлы мөнәсәбәтләрне императив тәртиптә җайга сала торган

нинди дә булса нигезләмәләрне үз эченә алмый, милекчеләрнең үз ихтыярларыннан башка, финанслау күпфатирлы йортлардагы торак урыннарның милекчеләренә йөкләнгән хезмәт күрсәтү форматында видеокүзәтү оештыруны күздә тоткан сервис моделен куллануны күздә тотмый, һәм, димәк, гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды хокукый нормаларның формаль билгеләнеше аларның җитәрлек дәрәҗәдә төгәллеген күздә тотуын, шуның белән аларны дөрес аңлау һәм бертөрле куллану тәэмин ителүен билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Хокукый норманың мәҗбүрилегенә, яки, киресенчә, аның тәкъдим итү характерында булуына карата күрсәтмәнең төгәл булмавы яки төрлелеге, аны хокукый дәүләтнең конституциячел принциплары белән килешми торган ирекле һәм дискриминацион куллануга китерергә мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, үзләренең хокукый җайга салуын гамәлгә ашырганда, хокук куллану практикасында аларны төрле мәгънәдә аңлату мөмкинлеген калдырмаслык итеп, хокукый нормаларны формалаштырырга кирәк, бу очракта, аерым алганда, тәкъдим итү характерындагы нормаларга императив форма бирелер иде.

5. Шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә хокук Россия Федерациясе Конституциясе белән гарантияләнә (23 статьяның 1 өлеше). Шундый ук гарантияләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 36 статьясындагы беренче өлешендә беркетелгән. Әлеге конституциячел нормалар, үз чиратында, Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциянең 8 статьясындагы беренче пункты нигезләмәләренә туры килә.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, хосусый тормышның кагылгысызлыгына хокук дигәндә, кешегә бирелгән һәм дәүләт тарафыннан гарантияләнгән, үзе турындагы мәгълүматны контрольдә тоту, шәхси, интим характердагы белешмәләрне таратуга каршы

тору мөмкинлеген аңлата; «хосусый тормыш» төшенчәсенә кеше тормышының аерым затка караган өлкәсе керә, ул аның үзенә генә кагыла, һәм, әгәр дә ул хокукка каршы булмаса, җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан һәм контрольдә тотылырга тиеш түгел (2005 елның 9 июнендәге 248-О номерлы, 2010 елның 26 гыйнварындагы 158-О-О номерлы, 2017 елның 28 сентябрендәге 2211-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Һәркемнең шәхси һәм гаилә тормышын хөрмәт итү хокукын гарантияләп, Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциянең 8 статьясы шуның белән бергә, мондый катнашлык законда каралган очракларда һәм демократик җәмгыятьтә милли куркынычсызлык һәм җәмәгать тәртибе, илнең икътисади тормыш дәрәҗәсе мәнфәгатьләрендә, тәртипсезлекләрне яки җинаятьләрне булдырмау, башка затларның сәламәтлеген яки әхлагын саклау яисә хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында кирәк булганда, гавами хакимиятләр тарафыннан бу хокукны гамәлгә ашыруга тыкшынуга юл куя.

Россия Федерациясе Конституциясенең 55 статьясындагы 3 өлеше мәгънәсе буенча хосусый тормыш хокукы шулай ук абсолют түгел һәм конституциячел төзелеш нигезләрен, башка затларның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, илнең оборонасын һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү максатларында кирәк булган кадәр генә чикләнергә мөмкин.

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гражданның сурәтен халыкка чыгару һәм киләчәктә дә куллануга ризалыгы (шул исәптән ул сурәтләнгән видеоязмалар), сурәтне куллану дәүләт, җәмәгать яисә бүтән гавами мәнфәгатьләрдә гамәлгә ашырылган очракларда, теләсә кем йөри ала торган ачык урыннарда уздырыла торган чараларда төшерелгән граждан сурәтен куллануга ризалык таләп ителми, моңа сурәт төп куллану объекты булган очраклар керми (152.1 статьяның 1 пунктындагы 1 һәм 2 пунктчалары). Шул ук вакытта «“Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” Россия Федерациясе законын судлар тарафыннан куллану

практикасы турында» 2010 елның 15 июнендәге 16 номерлы Россия Федерациясе Югары Суды Пленумы карарындагы аңлатмалар нигезендә, иҗтимагый мәнфәгатьләргә аудитория тарафыннан күрсәтелгән теләсә нинди кызыксынуны түгел, ә, мәсәлән, җәмгыятьнең демократик хокукый дәүләткә һәм граждан җәмгыятенә, җәмәгать куркынычсызлыгына, әйләнә-тирә мохиткә куркыныч янавын ачыклау һәм ачу ихтыяҗын кертергә кирәк (25 пунктның өченче абзацы).

Дәгъва белдерелә торган 1 нче ярдәмче программада күрсәтелгәнчә, Казан шәһәренең торак фондында чаралар комплексын гамәлгә ашыру җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә, хокук бозуларны профилактикалауда, террорчылыкка каршы торуда, экстремизмны профилактикалауда аерым юнәлеш булып тора. 1 нче ярдәмче программаның III бүлеге нигезләмәләре буенча видеокүзәтү, функциональ билгеләнеше буенча, видеокүзәтү объектын реаль вакыт режимында оператив контрольдә тотуга, архив видеоязмаларын җыю, саклау һәм таратуга һәм вакыйгаларга видеоанализ ясау, объектларны тануга бүленә. Шул ук вакытта, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый акт нигезләмәләренең турыдан-туры эчтәлегеннән күренгәнчә, реаль вакыт режимында видеосурәттән ерактан файдалану мөмкинлеге бары тик җәмәгать урыннарында, паркларда һәм скверларда, җәмәгатьчелек фикерен белдерү урыннарында, муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында урнаштырылган камералардан трансляцияләнүче видеосурәтләргә карата гына рөхсәт ителә.

Димәк, карала торган муниципаль программа нигезләмәләре үзенең хокукый мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча күпфатирлы йортның уртак файдалану урыннарыннан читтә видеокүзәтү оештыруны, шулай ук чикләнмәгән затлар даирәсенең реаль вакыт режимында трансляцияләнә торган видеосурәтләргә үтемлелеген күз алдында тотмый.

Шулай итеп, видеокүзәтүне гамәлгә ашыруның максаты гражданнарның иминлеген тәэмин итү икәнлеген һәм үзеннән-үзе күпфатирлы йортлар территориясендә видеокүзәтүнең комплекслы

системасын кертү мондый йортлардагы биналар милекчеләренең бу хакта турыдан-туры ихтыяр белдерүеннән башка мөмкин түгеллеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең дә, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләр белән аларның шәхси тормышының кагылгысызлыгына карата конституциячел хокуклары бозылган дип тапмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасына 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләрен, күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымтаны, шулай ук аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча тулаем әлеге карарны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция суды «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә “Электрон Казан” мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карарын аны кабул итү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Моның белән Казан шәһәренең җирле администрациясеннән, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны

исәпкә алып, муниципаль программаларны кабул итү срогы турындагы таләпнең үтәлешен чынлыкта тәэмин итү бурычы алынмый.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 86-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**